ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.11.2020 ел Баулы шәһәре №218

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 14 августындагы 237 номерлы карары белән расланган Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2020 елның 16 гыйнварындагы 4 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 14 августындагы 237 номерлы карары белән расланган Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2020 елның 16 гыйнварындагы 4 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәе үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

Административ регламентның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бинаны торак бина, муниципаль һәм хосусый торак фондының торак бинасын яшәү өчен яраксыз дип (Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы милкендәге күпфатирлы йорттан тыш), күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә

реконструкцияләнергә тиешле дип тану, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты”

1нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) бинаны торак бина, муниципаль һәм хосусый торак фондының торак бинасын яшәү өчен яраксыз дип (Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы милкендәге күпфатирлы йорттан тыш), күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели»;

2нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «бинаны торак бина, муниципаль һәм хосусый торак фондының торак бинасын яшәү өчен яраксыз дип (Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы милкендәге күпфатирлы йорттан тыш), күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану »;

5нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата, шулай ук аларның вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәктә эшләүчеләргә, шулай ук Федераль законның 27.07.2010 № 210-ФЗ номерлы 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмаларга, шулай ук аларның вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, хезмәткәрләргә карата судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны, 210-ФЗ номерлы Федераль закон 15.1 статьяда күрсәтелгән гарызнамәне теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән документларны яисә мәгълүматны таләп итү яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган гамәлләрне башкару;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Баулы муниципаль районының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләр каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Бүлек, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакыты яисә тәртибе бозылу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Баулы муниципаль районының башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3

өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүчедән башта документлырны кабул итүдән яки хезмәт күрсәтүдән баш тартканда, аларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматны таләп итү (210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш). Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

5.2. «Шикаять кәгазь чыганакта, электрон рәвештә Бүлеккә, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы тиешле органга (алга таба - күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы) һәм шулай ук 210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмага язма рәвештә тапшырыла. Бүлек җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Башкарма комитетка тапшырыла. Күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210 нчы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1нче өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.

Бүлек, Бүлекнең вазыйфаи заты, муниципаль хезмәткәр, Бүлек җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, Баулы муниципаль районы сайты, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://www.uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аркылы җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән

кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»;

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне дәвамында каралырга тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмалар документларны кабул итеп алудан йә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуына яисә билгеләнгән срокларны бозуына карата шикаять белдерелгән очракта мөрәҗәгать итүчегә - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.4 Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) Бүлекнең, Бүлекнең вазыйфаи затының, Башкарма комитетның, Башкарма комитетның яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яисә) хезмәткәрләренең исеме, аларның нинди карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелүе;

2) мөрәҗәгать итүченең - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче - юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук контактлы телефон номеры (номеры), электрон почта адресы (адресы) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Бүлекнең, Бүлекнең вазыйфаи затының, Башкарма комитетның, Башкарма комитетның, аның муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче Бүлекнең, Бүлекнең вазыйфаи заты, Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәре, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, күпфункцияле үзәк хезмәткәре,

210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларының карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәүгә нигез булып торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) йә аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.»;

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятькә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

Шикаятькә аны биргән муниципаль хезмәтне алучы имза сала.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм, мөрәҗәгать итүченең теләсә, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндергән очракта, тулысынча яисә өлешчә хокук бозуларны бетерү максатларында күрелергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, әлеге бүлекнең 5.2 пункты нигезендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.8. Шикаять канәгатьләнергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта Бүлек, Башкарма комитет, КФҮ яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында башкарылган гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаятьне канәгатьләнергә тиешле булмаган дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән

карарның сәбәпләре турында дәлилләр, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Бүлекнең, аның вазыйфаи затларының, башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук МФЦ, КФҮ белгечләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.»;

Административ регламентка 1нче кушымтада:

-

- исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бинаның билгеләнгән таләпләргә туры килүенә бәяләү уздыру һәм торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында гариза”;

Административ регламентка 2нче кушымтада:

- исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бүлмәне (күпфатирлы йортны) тикшерү акты»;

- текст буенча «бинаны тикшергәннән соң» сүзләреннән соң (күпфатирлы йорт) сүзләрен өстәргә;

- «Торак урын торышын кыскача тасвирлау» сүзләреннән соң «тотып торучы төзелеш корылмалары» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров